Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
«Нижнебишевская средняя общеобразовательная школа»
Заинского муниципального района Республики Татарстан

Принято педагогическим советом
протокол от 31.08 2019г.№ 2

Введено приказом от 31.08 2019г. № 118
Директор МБОУ «Нижнебишевская СОШ»
_______________ С.В.Иванов

**Рабочая программа**

по предмету татарский язык для 1-4 классов
начального общего образования
МБОУ «Нижнебишевская СОШ» Заинского муниципального района РТ

Составители: Гараева Ф. М., Мухаметшина И.А., Халиуллина Г.М., Шишкина Р.И.
(учителя начальных классов, первой квалификационной категории)

Согласовано
Заместитель директора ____________ Т.М. Ситдикова
(Подпись)
от 31.08 2019г.

Рассмотрено
На заседании МО, протокол № 1 от 38.08 2019г.
Руководитель МО ____________ Г.М. Халиуллина
(Подпись)

с. Нижнее Бишево
2019г.

# Аңлатма язуы

**Грамотага әзерлек чоры** ике төп **максатка** ия:
- укучыларны гомумән уку процессын аңлап үзләштерүгә һәм аеруча уку техникасына (басма сүзне авазландыра белүгә) хәзерләү;
- язу процессын (сөйләмне язма билгеләр белән күрсәтүне) аңлап үзләштерүгә әзерләү.

**Әлифба чоры** түбәндәге **максатларга** ия:
- балаларны укырга һәм язарга өйрәтү;
- дөрес язу күнекмәләрен үзләштерүгә нигез салу;
- элементар орфографик мәгълүматлар бирү;

Дәресләрне оештырганда уен элементлары кергән алымнар куллану отышлы. Интеграл дәресләр уздыру вакытны экономияләргә, дәрестә күп эш башкарыргга мөмкинлек бирә. Әлифба чорында ук укучыларны ишетеп язарга күнектерә башларга кирәк.

**Бурычлар**:

Язу гигиенасы кагыйдәләре белән таныштыру, кагыйдәләрне даими үтәү гадәте тәрбияләү. Кешеләрнең әйтеп һәм язып сөйләшүләрен гомуми күзаллау. Матур итеп сөйләшә, укый һәм яза белү кирәклеген аңлау.

График схемалар ярдәмендә сөйләмне — җөмләләргә, җөмләне сүзләргә аеру, сүзләрне иҗек һәм авазларга таркату.

Барлык баш һәм юл хәрефләренең язылышы һәм аларның тоташтыруның төп сызыклары белән таныштыру һәм каллиграфик дөрес язарга өйрәтү.Авазларны сүздә тиешле язма хәрефләр белән күрсәтү.Сүздәге хәрефләрне, аларны тоташтырган сузыкларын өзмичә ритмик язуны(ас-ос) булдыру , дәфтәр юлларына хәрефләрне һәм сүзләрне, тигез ара калдырып, тигез, дөрес урнаштыру.Башта укытучы белән иҗек –аваз анализы ясаганнан соң, тора бара мөстәкыйль рәвештә сүзләр, җөмләләр язу.

Татар теле дәресенең **максаты**

-укучыларда уңышлы аралашу сәләте булдыру-әйтмә һәм язма сөйләмне үстерү, кара-каршы сөйләшү осталыгы, монолог төзү һәм шулай ук гомуми кулҗтура күрсәткече булган грамоталы язу күнекмәләре булдыру, укучыларны тел фәненең төп мәгълуматлары белән таныштыру һәм шулар нигезендә аларның тамга символик һәм логик фикерләвен үстерү, татар теленең башка телләр белән берлектә дөньяның фәнни картинасын тудыруда катнашуы,аның милләте саклап калуда, халыкның, шәхеснең үзенчәлеген югалтмауда ышанычлы нигез, җәмгыятнең яшәешенә зарури шарт булуы турында күзаллау барлыкка китерү.

**Бурычлары**

-балаларның сөйләм осталыгын, фикерләү сәләтен һәм иҗади хыялын үстерү, ана телендә аралашу максатына, бурычларына,шартларына туры килгән тел чаралары сайлый белергә, уй-фикерләрен төгәл белдерергә һәм әңгәмәдәше әйткәнне тәңгәл аңларга күнектерү

-телнең лексикасы,фонетикасы һәм грамматикасы буенча программада күрсәтелгән башлангыч белемнәрне үзләштерүгә ирешү

-укучыларда дөрес уку һәм язу күнекмәләре булдыру, диалогта катнашырга һәм аларны зур, катлаулы булмаган монолог тибында төзеп әйтергә, тасфирлама, хикәяләү, фикер йөртү төрендәге кечкенә текстлар төзергә өйрәтү, уңышлы аралашу сәләте тәрбияләү;

**Планлаштырылган нәтиҗәләр 1 сыйныф**

| Өйрәнелә торган бүлек | Предмет нәтиҗәләре | | Метапредмет (регулятив, коммуникатив, танып-белү) нәтиҗәсе | Шәхси нәтиҗәләр |
|---|---|---|---|---|
| | **Укучы өйрәнә** | **Укучы өйрәнү мөмкинчелеген ала** | | |
| **Графика, каллиграфия, орфография** | - хәрефләр белдергән авазларны транскрипция билгеләре белән язарга;<br>-сүзләргә төшеп калган хәрефләрне куеп язарга;<br>-авазларны һәм хәрефләрне аера белергә; | - проза һәм поэзия жанрына караган текстларны сәнгатьле итеп укырга;<br>-аралашу өчен бирелгән темаларга караган сүзләрнең дөрес әйтелешенә ирешү;<br>-җөмлә ахырында тыныш билгеләрен интонациягә бәйле рәвештә кую. | **Регулятив:** эшчәнлек өчен эш урынын әзерләү; укытучы ярдәме белән максат кую һәм эшне планлаштырырга өйрәнү.<br>**Танып белү:** фикерләрне логик чылбырга салу; иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү; фикерләрне логик чылбырга салу.<br>**Коммуникатив:** әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү; төркемнәрдә эшләгәндә уртак фикергә килә белү. | 1. Үзеңне Рәсәй гражданины итеп тою. Рәсәй халыкларының һәм дөнья халыкларының теленә, диненә, мәдәни мирасына хөрмәт белән карау.<br>2. Мотивация нигезендә белем алу һәм танып белүнең укучыларның үзлегеннән үсеш, үзлегеннән укып белем алуга әзерлек һәм мөмкинлекләре.<br>3. Шәхси сайлау нигезендә мораль (әхлакый) проблемаларны чишүдә компетентлык һәм камилләшкән мораль, аң, әхлакый хисләр һәм әхлакый тәртип |
| **Сөйләмнең фонетик ягы** | -сузык һәм тартык авазларны аеру<br>-яңгырау һәм саңгырау авазларны аеру.<br>-алар кергән сүзләрне дөрес әйтә һәм язу<br>-сүзләрне иҗекләргә бүлү<br>-укылган иҗекләр санын билгели белү. | - калын һәм нечкә сузыклар, аларны дөрес әйтү һәм язу күнекмәләрен камилләштерү;<br>- татар теленең үзенчәлекле сузыклары һәм аларны белдерә торган хәрефләрнең дөрес язылышын белергә | **Регулятив:** укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү;уку эшчәнлеген оештыра белү.<br>**Танып белү:** тиешле мәгълүматны таба белү; сөйләм берәмлекләрен логик чылбырга салу.<br>**Коммуникатив:** мәгълүматны туплау өчен күмәк эш башкару. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Сөйләмнең грамматик ягы. Исем** | - баш һәм юл хәрефләре белән язылучы сүзләр белән таныштыру.<br>-Кем? Нәрсә?сораулар ына җавап бирә белү. | - исемнәрнең берлек ,күплек сөйләмдә куллануны камилләштер ү<br>- кем? нәрсә? сорауларын кулланып, сорау бирә белүне камилләштер ү. | **Регулятив**: укытучы ярдәме белән максат кую һәм эшне планлаштырырга өйрәнү,уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү.<br>**Танып белү:** объектларны чагыштыру,классификация ләү өчен уртак билгеләрне билгеләү,эш башкару ысулларына һәм шартларына анализ ясау.<br>**Коммуникатив:** әңгәмәдәшеңнең аралашу холкы белән идарә итү. | (үзеңне тоту) , үз гамәлләреңә аңлы һәм җаваплы караш формалашты ру.<br>4. Башка кешегә, аның уй-фикеренә, дөньяга карашына, мәдәниятенә, теленә, диненә карата аңлы, хөрмәтле һәм игелекле караш булдыру. Башка кешеләр белән диалог оештырырга әзер һәм сәләтле булу һәм үзара аңлашуга ирешү .<br><br>5.Төркемнәрд ә һәм җәмгыятьнең төрле оешмаларынд а үзеңне тоту кагыйдәләрен үзләштерү; оештыру эшчәнлегенд ә компетентлы к кыйммәтләре н үзләштерү; бердәм башкарыла торган эшчәнлеккә уңай караш тудыру; |
| **Сыйфат.** | -сыйфатның гади дәрәҗәсен белү һәм аеру. сөйләмдә куллану<br>- нинди?соравын а җавап бирә белү. | - сыйфатның гади дәрәҗәсен сөйләмдә кулланышын камилләштер ү. | **Регулятив:** укудагы уңышларның,уңышсызлар ның сәбәбен аңлый,анализлый белү.<br>**Танып белү:** уку максатын иөстәкыйль билгеләү,төп һәм ярдәмчел билгеләрне аеру, анализлау.<br>**Коммуникатив:** коммуникатив мәсьәләгә таянып фикерне төгәл итеп җиткерү, мәгълүматны туплау өчен күмәк эш башкару. | |
| . | | | **Регулятив:** уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белүукытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү.<br>**Танып белү:** эш башкару ысулларына һәм шартларына анализ ясау,классификация өчен уртак билгеләрне билгеләү.<br>**Коммуникатив:** әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый белү,әңгәмәдәшең белән аралашу калыбын төзү. | |
| | | | **Регулятив:** укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү, уку эшчәнлеген оештыра белү.<br>**Танып белү:** иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү,аларны чишү | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | өчен алгоритм булдыру. **Коммуникатив:**әңгәмәдә шеңнең фикерен тыңлый белү,аралашу кабылын төзү. | үзеңдә лидерлык сыйфатларын тормышка ашыру |
| **Фигыль.** | -хәзерге заман хикәя формасын белү; Предметны, эш-хәрәкәтне, билгене белдергән сүзләр турында белемнәрен гомумиләштерү , кабатлау Кем? Нәрсә? Нишли? Нишләде? Нинди? Кайсы? сорауларына җавап булган сүзләр турында белү; | . Предметның үзен аның билгесен , эш-хәрәкәтен белдергән сүзләргә карата дөрес сорау кую, Җөмләдә кем? нәрсә? Нишли? нинди? нинди? кайсы? сорауларына җавап булган сүзләне таба белү; | **Регулятив:** уку хезмәтендә үзеңә максат куя белү,бурычларны билгели белү, укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү. **Танып белү:** сөйләм берәмлекләрен логик тәртипкә салу,иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү,аларны чишү өчен алгортм булдыру,объектларны чагыштыру **Коммуникатив:**мәгълүмат ны туплау өчен,күмәк эш башкару, әңгәмәдәшеңнең аралашу холкы белән идарә итү, коммуникатив мәсьәләгә таянып,фикерне төгәл итеп җиткерү. | ысулларын формалашты ру. 6. Сәламәт һәм куркынычсыз яшәү рәвеше кыйммәтләре нең формалашуы н, үз-үзенне тоту,юлларда , транспорта үзеңне тоту кагыйдәләрен формалашты ру. 1. Үзеңне Рәсәй гражданины итеп тою. |
| | | | **Регулятив:** укытучы ярдәме белән макста кую һәм эшне планлаштырырга өйрәнү,эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра белү,уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү. **Танып белү:** тиешле мәгълүматны билгеләү, анализлау,объектларны чагыштыру,классификация ләү өчен уртак билгеләрне билгеләү,эш башкару ысулларына һәм шартларына анализ ясау. **Коммуникатив:** әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый белү, әңгәмәдәшең белән аралашу калыбын төзү, мәгълүматны туплау өчен күмәк эш башкару. | Рәсәй халыкларыны ң һәм дөнья халыкларыны ң теленә, диненә, мәдәни мирасына хөрмәт белән карау. 2. Мотивация нигезендә белем алу һәм танып белүнең укучыларның үзлегеннән үсеш, үзлегеннән укып белем алуга әзерлек һәм мөмкинлеклә ре. |
| | | | **Регулятив:** уку хезмәтендә үзеңә максат куя белү,бурычларны | 3. Шәхси сайлау |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Синтакси с.** | -җөмлә, җөмлә башы, ахыры төшенчәсен аңлау; | - җөмлә баш хәрефтән языла, җөмлә тәмамлангач, тыныш билгесе куелуын дөрес куллану. | билгели белү, эш тәртибен аңлап,уку эшчәнлеген оештыра белү.<br>**Танып белү:** фикерләрне логик чылбырга салу,иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы чишү ысулларын мөстәкыйль рәвештә булдыру, эш башкаруның ысулларына һәм шартларына анализ ясау.<br>**Коммуникатив:**әңгәмәдә шеңнең фикерен тыңлый белү, әңгәмәдәшең белән аралашу калыбын төзү. | нигезендә мораль (әхлакый) проблемалар ны чишүдә компетентлы к һәм камилләшкән мораль, аң, әхлакый хисләр һәм әхлакый тәртип (үзеңне тоту) , үз гамәлләреңә аңлы һәм җаваплы караш формалашты ру<br>4. Башка кешегә, аның уй-фикеренә, дөньяга карашына, мәдәниятенә, теленә, диненә карата аңлы, хөрмәтле һәм игелекле караш булдыру. Башка кешеләр белән диалог оештырырга әзер һәм сәләтле булу һәм үзара аңлашуга ирешү .<br>5.Төркемнәрд ә һәм җәмгыятьнең төрле оешмаларынд а үзеңне тоту кагыйдәләрен үзләштерү; оештыру |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | эшчәнлегендә компетентлык кыйммәтләрен үзләштерү; бердәм башкарылаторган эшчәнлеккә уңай караш тудыру; үзеңдә лидерлык сыйфатларын тормышка ашыру ысулларын формалаштыру. 6. Сәламәт һәм куркынычсыз яшәү рәвеше кыйммәтләренең формалашуын, үз-үзенне тоту,юлларда, транспорта үзеңне тоту кагыйдәләрен формалаштыру |

**Фәнне укытуның планлаштырылган нәтиҗәсе 2класс**

| Бүлекнең исеме | Фән нәтиҗәләре | | Метапредмет нәтиҗәсе | Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр |
|---|---|---|---|---|
| | Укучы өйрәнә | Укучы өйрәнә ала | | |
| Фонетика һәм орфоэпия | Россиядә тел һәм мәдәният киңлегенең бердәмлеге һәм күптөрлелеге, | Партадаш күрше белән хезмәттәшлектә яңа уку мәсьәләләре | ТБУУГ:аваз һәм хәрефләрне анализлый, алар | үз уңышлары яки уңышсыз-лыкларының сәбәпләре турында фикер йөртү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | телнең милли үзаң формалаштыру нигезе булуы турында беренчел күзаллау булдыра | н куярга | арасындагы аермалы якларны таба белү;<br>РУУГ:1 класста үзләштергән белемнәргә таянып, яңа информацияне таба белергә күнектерү;<br>КУУГ:үз фикереңне нигезли, дәлилли белү. | |
| Графика | Телне милли мәдәният күренеше һәм аралашуның төп чарасы дип, татар телен милләтара аралашу теле итеп танырга | Уку эшчәнлегенең үзең өчен әһәмиятен бәяләргә | ТБУУГ:калын һәм нечкә сузыкларны анализлый, алар арасындагы охшаш һәм аермалы якларны таба белү;<br>РУУГ: уку мәсьәләсен кабул итү һәм аны эш дәвамында саклау;<br>КУУГ:үз фикереңне төгәл, аңлаешлы итеп әйтү, аны яклау. | дәрестә үзенең белем һәм күнекмәләрен куллану |
| Сүз | Татар әдәби теле нормалары (орфоэпик, лексик, грамматик, орфографик, пунктуация), сөйләм әдәбе кагыйдәләре турында беренчел күзаллауга ия булырга | Уку эшчәнлегенең үзең өчен мәгънәсен һәм сарыф ителгән вакытны, көчне бәяләргә | ТБУУГ:кирәкле информацияләрне дәреслектән таба белү;<br>РУУГ: уку мәсьәләсен кабул итү һәм аны эш дәвамында саклау;<br>КУУГ:үзара ярдәм итешү, үз фикереңне | үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | нигезли, дәлилли белү. | |
| Җөмлә | Хатасыз язуны культура дәрәҗәсенең бер күрсәткече итеп тану; үзе төзегән һәм тәкъдим ителгән текстларны язганда, орфография һәм тыныш билгеләре кагыйдәләрен дөрес куллана белергә | Яңа уку мәсьәләсен чишүгә керешкән-че үз мөмкинлек-ләрен мөстәкыйль бәяләргә | ТБУУГ:кирәкле информацияләрне дәреслектән таба белү; РУУГ: укучылар тарафыннан белгән яки әлегәчә белмәгән күнекмәләрне үзара бәйләү булдыру. КУУГ:үзара ярдәм итешү, үз фикереңне нигезли, дәлилли белү. | үз мөмкинлекләреңне чамалау, үзеңне читтән күрү |
| Бәйләнешле сөйләм | Аралашу вакытында куелган максат һәм бурычтан чыгып, өйрәнгән материалны куллана белергә; катлаулы булмаган монологик сөйләм һәм язма текстлар төзегәндә, коммуникатив бурычларны уңышлы үтәү өчен, туры килгән тел чараларын сайлый белергә | Ирешеләчәк нәтиҗәне алдан фаразлаарга | ТБУУГ:җыелган мәгълүматны бербөтен итеп туплау. РУУГ:кагыйдәләрне истә тоту, шуларга ияреп гамәлләр кылу. КУУГ:фикерләү сәләтен үстерү, карарлар кабул итү һәм аны тормышка ашыру. | үз мөмкинлекләреңне чамалау, үзеңне читтән күрү |

**Татар теле буенча планлаштырылган нәтиҗәләр 3 сыйныф**

| **Өйрәнелә торган бүлек** | **Предмет нәтиҗәсе** | | **Метапредмет нәтиҗәсе** | **Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр** |
|---|---|---|---|---|
| | **Укучы өйрәнә** | **Укучы өйрәнү мөмкинчелеген ала** | | |
| **Графи** | - татар теленә хас | - | **Регулятив күнекмә.** | 1. Үзеңне Рәсәй |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **ка, каллиграфия, орфография** | булган авазларны ишетә һәм дөрес әйтә белергә;<br>- авазларны һәм хәрефләрне аера белергә;<br>- хәрефләр белдергән авазларны транскрипция билгеләре белән язарга;<br>- җөмлә чикләрен таба алырга, язуда күрсәтә белергә;<br>- сүзләргә төшеп калган хәрефләрне куеп язарга;<br>- сүзләрне юлдан юлга күчереп язарга. | фонетиканың төрле сәнгатьле уку чараларын аеру;<br>- транскрипция билгеләре белән язу. | **1. Мөстәкыйль рәвештә максатка ирешү юлларын, шулай ук альтернатив юлларын планлаштыра белү:** проблеманы чишү планын төзү (проект өстендә эш), уку һәм танып-белү мәсьәләләрен чишүнең шартларын, шулай ук бирелгән вариантлардан таба, белү.<br>**2.Үзеңнең чынбарлыкны үзгәртүгә юнәлтелгән адымыңны планлаштырылган нәтиҗәләр белән тиңләштерә белү:** педагог һәм яшьтәшләре белән бергә уку эшчәнлеген бәяләү һәм көтелгән нәтиҗәләрнең критерийларын билгели белү;<br>үз эшчәнлегеңнең бәяләү инструментларын сайлау, тәкъдим ителгән шартлар һәм таләпләр рамкасында эшчәнлегеңә үзконтроль ясау.<br>**3. Уку мәсьәләләренең дөреслегенә, аны чишкәндәге үз мөмкинлекләреңә бәя бирә белү:** уку мәсьәләләрен бәяләү критерийларының дөреслеген билгели белү;максаттан чыгып, нәтиҗә һәм гамәл ысулларын аера, эшләнелгән бәя һәм үзбәя критерийларын | гражданины итеп тою: ватандарлык, Ватанга, күпмилләтле Рәсәй халыкларының үткәненә, бүгенгесенә хөрмәт.<br>Үзеңне милләтеңнең вәкиле итеп тану; туган телеңнең, туган төбәгеңнең, милләтеңнең тарихын һәм мәдәни мирасын белү.<br>2. Мотивация нигезендә белем алу һәм танып белүнең укучыларның үзлегеннән үсеш, үзлегеннән укып белем алуга әзерлек.<br>3. Шәхси сайлау нигезендә мораль (әхлакый) проблемаларны чишүдә компетентлык һәм камилләшкән мораль аң, үз гамәлләреңә аңлы һәм җаваплы караш формалаштыру, кешеләрнең дини карашларына, хисләренә хөрмәт белән карау.<br>Укуга җаваплы караш, хезмәткә хөрмәтле караш формалаштыру, социаль кирәкле хезмәттә катнашу. Кеше тормышында һәм җәмгыятьтә гаиләнең кирәклелеген аңлау, гаилә әгъзаларына хөрмәт белән караш һәм кайгыртучан мөнәсәбәт.<br>4. Заманча дөньяның социаль, мәдәни, тел, рухи төрлелеген истә тотып, дөньяга тулы бер караш булдыру.<br>5. Башка кешегә, аның уй-фикеренә, дөньяга карашына, мәдәниятенә, теленә, диненә, карата аңлы, хөрмәтле һәм игелекле караш булдыру.<br>6.Гомумкешелек |
| **Сөйләмнең фонетик ягы** | - татар теленең барлык авазларын дөрес әйтә белергә;<br>- сузык һәм тартык авазлар составын таный белергә;<br>- телдән сөйләм яисә кычкырып уку барышында, татар теленә хас авазларның әйтелеш нормаларын сакларга;<br>- сүз басымын дөрес куеп укырга; | - проза һәм поэзия жанрына караган текстларны сәнгатьле итеп уку;<br>транскрипция буенча сүзләрне уку. | | |
| **Сөйләмнең лексик ягы** | - телдән һәм язма сөйләмдә программага кертелгән лексик берәмлекләрне дөрес әйтергә һәм кулланырга;<br>- сүзләрнең синонимнарын һәм антонимнарын табарга;<br>- сүзләрне тематикага карап берләштерергә(аерып алырга); | -телдән һәм язма сөйләмдә лексик нормаларны саклау;<br>сөйләмне бәйләнешле итү чарасы буларак файдалану. | | |

<table>
<tr><td></td><td>- сүзләргә ялганган аффиксларның төрләрен танырга, аерырга.</td><td></td><td rowspan="4">иркен куллана белү.<br>4. Үзконтроль нигезләрен яхшы белү, уку һәм танып-белү процессында үзбәя, карар кабул итүне аңлы рәвештә сайлый белү: бер-береңне тикшерү процессында үзеңнең, башкаларның уку һәм танып-белү эшчәнлеген күзәтә, анализлый белү; уку ситуацияләрендә карар кабул итә белү һәм җаваплылык хисе тою.<br>Танып-белү күнекмәсе.<br>5. Төшенчәләрне билгели, йомгаклый, аналогияләрне таба, сәбәп-нәтиҗә элемтәләрен урнаштыра, логик фикерләү күнекмәләре: мөһим һәм аннан бәйле сүзләрдән торган логик чылбыр төзү;<br>ике яки берничә предметның, күренешнең гомуми билгесен табу, аларның охшашлыгын аңлату;<br>аерым билгеләре буенча предмет һәм күренешләрне берләштерү, чагыштыру, классификацияләү,<br>факт һәм күренешләрне гомумиләштерү; фикер йөртүне предметларны һәм күренешләрне чагыштыру һәм гомуми билгеләрне аерып алу нигезендә төзү.<br>6. Уку һәм танып-белү мәсьәләләрен чишү өчен билге,</td><td rowspan="4">нормаларын белү, төркемнәрдә һәм җәмгыятьнең төрле оешмаларында үзеңне тоту кагыйдәләрен үзләштерү;<br>яшүсмерләрнең иҗтимагый оешмаларында катнашырга әзер тору; бердәм башкарыла торган эшчәнлеккә уңай караш тудыру;<br>башка шәхескә хөрмәт;<br>анализ ясау, проектлаштыру эшчәнлеген оештыру;<br>үзеңдә лидерлык сыйфатларын тормышка ашыру ысулларын формалаштыру.<br>7. Сәламәт һәм куркынычсыз яшәү рәвеше кыйммәтләренең формалашуы; кеше тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янаучы (тудыручы) гадәттән тыш хәлләрдә коллектив һәм индивидуаль уз-үзенне тоту, юлларда, транспортта үзеңне тоту кагыйдәләрен формалаштыру.<br>8. Дөнья һәм Рәсәй халыкларының сәнгать мирасын аңлау, эстетик характердагы иҗади эшчәнлекне үзләштерү аша: төрле этномәдәни гореф-гадәтләрне чыгалдыручы әдәби әсәрләрне аңлау сәләте; гомуми рухи мәдәният, тормышны танып-белүнең үзенчәлекле ысулы һәм аралашуны оештыру чаралары буларак, укучыларда әдәби культура нигезләрен</td></tr>
<tr><td>Сүз ясалышы</td><td>- бирелгән сүздән (тамырдан) төрле сүзләр ясарга;<br>- сүз ясалышы буенча күнекмәләрне дөрес язуда кулланырга;<br>- күп мәгънәле сүзләрне таный белергә.</td><td>- сүз ясалуга караган сүзлекләр һәм белешмә материалдан (мультимедия чараларыннан) кирәкле мәгълүматны табу.</td></tr>
<tr><td>Сөйләмнең грамматик ягы. Исем</td><td>- татар телендәге исем сүз төркемен аера белергә;<br>- исемнәрне берлек һәм күплек санда, тартым һәм килеш формаларында текстта тану һәм сөйләмдә кулланырга;<br>- исемнең сан, тартым, килеш кушымчаларын сөйләмдә урынлы кулланырга;<br>- ялгызлык һәм уртаклык исемнәрне үзләштерергә;<br>- исемнәргә кушымчалар ялгану тәртибен үзләштерергә.</td><td>- дустың турында сөйли белү;<br>- публицистик һәм әдәби жанрдагы текстларда исемнәрне тану;<br>- кагыйдәгә нигезләнеп тамыр, кушма, парлы, тезмә исемнәр ясау һәм сөйләмдә куллану.</td></tr>
<tr><td>Сыйфат</td><td>- сыйфатның гади, чагыштыру һәм артыклык, кимлек дәрәҗәләрен ясый һәм аера белергә;<br>- бирелгән сүздән (тамырдан) төрле сүзләр ясарга;<br>- татар телендәге сыйфат сүз төркемен аера белергә;</td><td>- төрле сүзлекләрдән һәм мультимедия чараларыннан сыйфатларга кирәкле мәгълүматны эзләп табу;</td></tr>
</table>

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | - кагыйдәгә нигезләнеп төрле дәрәҗәдәге сыйфатлар ясау һәм сөйләмдә кулланырга. | | **символ, модель, схемаларны үзгәртү һәм куллана белү күнекмәсе:** предмет һәм күренешләрне билге һәм символлар белән билгели; предмет һәм күренешләр арасындагы логик бәйләнешне билгели, аларны билге, схемалар аша күрсәтү; мәсьәләнең шарты яки чишелү ысулы нигезендә модель, схема төзү.<br>**7. Аңлап уку:** үз эшчәнлеге максатларына туры килгән, соралган информацияне тексттан табу.<br>**8. Экологик фикерләүне формалаштыру һәм үстерү, аны танып-белү:** табигый тирәлеккә үзенең мөнәсәбәтен билгели белү;<br>экологик белемнәрне тарату,<br>проект эшләр, модельләр, сочинениеләр, рәсемнәр аша табигатькә үз мөнәсәбәтеңне белдерү.<br>**9. Сүзлекләр, башка эзләнү схемаларын актив куллана белү сәләтен мотивлаштыруны үстерү**: кирәкле мөһим эзләнә торган сүзләрне билгеләү; эзләү нәтиҗәләрен үз эшчәнлегең белән чагыштырып карау.<br>**Коммуникатив күнекмә.** | формалаштыру; әйләнә-тирә дөньяны эстетик, эмоциональ кыйммәт аша күзаллау; үз-үзеңне күрсәтү һәм мәдәниятнең әдәби, әхлакый киңлегендә ориентлаша белү сәләте; кеше матурлыгын аңлау аша, үз илеңнең мәдәният тарихына хөрмәт; әдәби әсәрләрне өйрәнү ихтыяҗы булу; мәгънәви, эстетик һәм шәхескә юнәлтелгән кыйммәт буларак, әдәби мәдәниятнең гореф-гадәтләренә актив мөнәсәбәт формалаштыру. |
| **Алмашлык** | - татар телендәге алмашлык сүз төркемен килеш белән төрләнешен белергә;<br>- зат алмашлыкларын хәзерге татар әдәби теле нормалары кысаларында кулланырга;<br>- зат, сорау, билгеләү (үз), текстта танырга һәм сөйләмдә кулланырга. | - алмашлыклар кулланып җөмләләр төзү;<br>- алмашлыклар кулланып, хикәяне тулыландыру. | | |
| **Фигыль** | - татар телендәге фигыль сүз төркемен аера белергә;<br>- фигыль сүз төркеменең төрле формаларын хәзерге татар әдәби теле нормалары кысаларында кулланырга;<br>- хикәя һәм боерык фигыльләрне текстта тану һәм сөйләмдә куллану.<br>- хикәя фигыльнең заман формаларын аерырга;<br>- барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләнешен белергә; | - хикәя фигыльнең заман формаларын белү;<br>- үтенүне белдерүче фигыльләрне танырга һәм сөйләмдә куллану. | | |
| **Бәйлекләр** | - белән, шикелле, турында, өчен, кебек кадәр, соң, аша бәйлекләренең исемнәр һәм алмашлыклар белән кулланырга;<br>- бәйлек һәм бәйлек | - бәйлекләр кулланып җөмләләр төзү;<br>- рус теленнән аермалы буларак, | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | сүзләрне (алдында, артында, астында, өстендә, эчендә, янында) җөмләдә кулланырга. | бәйлекләрнең сүздән соң килүен аңлау, сөйләмдә дөрес куллану. | **10. Укытучы һәм яшьтәшләре белән бердәм эшчәнлекне оештыра, индивидуаль һәм төркемдә эшли белү күнекмәсе булдыру. Дәлилле итеп үз фикерен башкаларга җиткерә белү:** бердәм эшчәнлектә мөмкин булган рольләрне билгели белү; бердәм эшчәнлектә билгеле бер рольне башкара белү; әңгәмәдәшченең позициясен аңлау һәм кабул итә белү; төркемдә уку эшчәнлеген оештыра белү (гомуми максатлар билгели белү, рольләрне бүлешү, бер-берең белән уртак фикергә килү. **11. Үз хисләреңне, фикерләреңне бирү, үз эшчәнлегеңне планлаштыру; язма һәм телдән, монологик һәм контекст сөйләм төрләрен оста файдалана белү:** коммуникация бурычларын билгели белү һәм аңа туры килгән сөйләм чараларын сайлап ала белү; башка кешеләр белән коммуникация барышында сөйләм чараларын сайлап ала һәм куллана белү (парлы диалог, кече төркемдә); диалог барышында үз фикереңне дәлилләп бирә, партнер фикерен сорый белү. | |
| **Кисәкчәләр** | мы/-ме, бик, түгел, тагын, әле кисәкчәләрнең дөрес язылышын анализларга, сөйләмдә кулланырга. | - кагыйдәгә нигезләнеп төрле кисәкчәләрне сөйләмдә куллану;<br>- кисәкчәләр кулланып җөмләләр төзү. | | |
| **Синтаксис** | -җөмләнең мәгънәви төркемнәргә бүленешен аера белергә;<br>-раслау һәм инкяр җөмләләрне аерырга. | - җыйнак һәм җәенке җөмләләрне тану, аера белү, язма сөйләмдә куллану. | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | **12.Информацион-коммуникатив технологияләр өлкәсендә компетентлыкны формалаштыру һәм үстерү:** уку һәм практик мәсьәләләрне чишү өчен кирәкле информацион ресурсларны ИКТ чаралары аша эзләргә һәм максатчан кулланырга; информацион һәм коммуникатив уку мәсьәләләрен чишү өчен,шулай ук: сочинение, презентацияләүдә компьютер технологияләрен куллана белү) | |

**Татар теле буенча планлаштырылган нәтиҗәләр 4 сыйныф**

| Бүлек исеме | Предмет нәтиҗәләре | | Метапредмет нәтиҗәләр | Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр |
|---|---|---|---|---|
| | Укучы өйрәнәчәк | Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак | | |
| Сыйныфларда үткәннәрне кабатлау. | -аваз һәм хәрефләрне аера;<br><br>- ана теленең авазларын һәм хәрефләрен, аларның әйтелеш һәм язылыш | -үз сөйләмендә татар әдәби тел нормаларын саклый һәм әңгәмәдәшенең сөйләмендә бу нормаларның дәреслектә бирелгән | Регулятив күнекмә.<br><br>-теләсә нинди эшчәнлектә иң беренче проблеманы аерып ала, аның чишелеш юлларын билгели, иң эффектив чишелеш юлын аерып ала, | -үзеңне Рәсәй гражданины итеп тою: ватандарлык, Ватанга, күпмилләтле Рәсәй халыкларының үткәненә, бүгенгесенә хөрмәт, рус теле һәм Рәсәй |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Фонетика. Орфоэпия. Графика. | үзенчелекләрен аңлый, авазларга характеристика бирә ала;<br><br>- хәрефләрнең алфавитта урнашу тәртибен һәм, кирәкле мәгълүматны табу өчен, алфавитны куллана ала. | материал күләмендә үтәлүен бәяли;<br><br>- сүзгә басым куйганда яки сүзнең дөрес әйтелешендә икеләнү туган очракта, дәреслектәге сүзлек буенча мөстәкыйль рәвештә җавап таба яки укытучысына һәм әти-әнисенә мөрәҗәгать итә ала. | аерып алынган проблеманы мөстәкыйль хәл итә: булган белем нәтиҗәсен анализлый, киләчәк нәтиҗәне планлаштыру;<br><br>үз проблемаларын тиңләштерү, төп проблеманы билгеләү.<br><br>-мөстәкыйль рәвештә максатка ирешү юлларын, шулай ук альтернатив юлларын планлаштыра белү: проблеманы чишү планын төзү (проект өстендә эш), уку һәм танып-белү мәсьәләләрен чишүнең шартларын, шулай ук бирелгән вариантлардан таба, белү.<br><br>-үзеңнең чынбарлыкны үзгәртүгә юнәлтелгән адымыңны планлаштырылган нәтиҗәләр белән тиңләштерә белү: педагог һәм яшьтәшләре белән бергә уку эшчәнлеген бәяләү һәм көтелгән нәтиҗәләрнең критерийларын билгели белү;<br><br>үз эшчәнлеген бәяләү һәм көтелгән нәтиҗәләрнең критерийларын билгеле бер системага салу (шулай ук өстен | халыклары телләренең кулланылышта булуының әһәмияте.<br><br>Үзеңне милләтеңнең вәкиле итеп тану; туган телеңнең, туган төбәгеңнең, милләтеңнең тарихын һәм мәдәни мирасын белү.<br><br>Рәсәй халыкларының һәм дөнья халыкларының теленә, диненә, мәдәни мирасына хөрмәт белән карау.<br><br>-мотивация нигезендә белем алу һәм танып белүнең укучыларның үзлегеннән үсеш, үзлегеннән укып белем алуга әзерлек.<br><br>-шәхси сайлау нигезендә мораль (әхлакый) проблемаларны чишүдә компетентлык һәм камилләшкән мораль аң, үз гамәлләреңә аңлы һәм җаваплы караш формалаштыру, кешеләрнең дини карашларына, хисләренә хөрмәт белән карау. |
| Лексикология | -мәгънәсе ачыклану таләп итәлә торган сүзләрне табарга;<br><br>-текст буенча сүзләрнең мәгънәсен аера яисә аны аңлатмалы сүзлек ярдәмендә ачыкларга өйрәнә. | *-текстларда кабатлаулар булдырмас өчен, кирәкле синонимнар, антонимнар табу, текстта туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләрне билгеләү, аларның урынлы кулланылышын бәяләү, тәкъдим ителгән сүзләр арасыннан тиешлесен сайлап алу мөмкинлеге ала.* | | |
| Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы (морфемика) | -тамырдаш сүзләрне һәм сүз формаларын | *-дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча кушымчаларн* | | |

<table>
<tr><td></td><td>аерырга;<br><br>-сүзнең тамыр һәм кушымчаларын (аффиксларын) табарга өйрәнә.</td><td>ың чикләре ачык күренеп торган сүзләрнең төзелешен тикшерү һәм аның дөреслеген бәяләү мөмкинлеге ала.</td><td rowspan="3">булганнарын сайлый белү);<br><br>үз эшчәнлегеңнең бәяләү инструментларын сайлау, тәкъдим ителгән шартлар һәм таләпләр рамкасында эшчәнлегеңә үзконтроль ясау.<br><br>-уку мәсьәләләренең дөреслегенә, аны чишкәндәге үз мөмкинлекләреңә бәя бирә белү:уку мәсьәләләрен бәяләү критерийларының дөреслеген билгели белү; максаттан чыгып, нәтиҗә һәм гамәл ысулларын аера, эшләнелгән бәя һәм үзбәя критерийларын иркен куллана белү.<br><br>-үзконтроль нигезләрен яхшы белү, уку һәм танып-белү процессында үзбәя, карар кабул итүне аңлы рәвештә сайлый белү: бер-береңне тикшерү процессында үзеңнең, башкаларның уку һәм танып-белү эшчәнлеген күзәтә, анализлый белү; уку ситуацияләрендә карар кабул итә белү һәм җаваплылык хисе тою.<br><br>Танып-<br>белү күнекмәсе.<br><br>-төшенчәләрне билгели, йомгаклый,</td><td rowspan="3">Укуга җаваплы караш, хезмәткә хөрмәтле караш формалаштыру, социаль кирәкле хезмәттә катнашу. Кеше тормышында һәм җәмгыятьтә гаиләнең кирәклелеген аңлау, гаилә әгъзаларына хөрмәт белән караш һәм кайгыртучан мөнәсәбәт.<br><br>-заманча дөньяның социаль, мәдәни, тел, рухи төрлелеген истә тотып, дөньяга тулы бер караш булдыру.<br><br>-башка кешегә, аның уй-фикеренә, дөньяга карашына, мәдәниятенә, теленә, диненә, карата аңлы, хөрмәтле һәм игелекле караш булдыру. Башка кешеләр белән диалог оештырырга әзер һәм сәләтле булу һәм үзара аңлашуга ирешү.<br><br>-гомумкешелек нормаларын белү, төркемнәрдә һәм җәмгыятьнең төрле оешмаларында үзеңне тоту кагыйдәләрен</td></tr>
<tr><td>Морфология</td><td>-исемнәрнең сан, килеш һәм тартым белән төрләнешен;<br><br>-<br>сыйфатларның лексик-семантик һәм морфологик-синтаксик үзенчәлекләрен<br><br>-фигыльнең лексик-семантик үзенчәлекләрен өйрәнә.</td><td>-дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча исемгә, сыйфатка, фигыльгә морфологик анализ ясау һәм аның дөреслеген бәяләү, тексттан алмашлык, рәвеш, бәйлек сүзләр, кисәкчә, теркәгечләрне, фигыльләрдәге юклык кушымчаларын (-ма / -мә) табу мөмкинлеге ала.</td></tr>
<tr><td>Синтаксис</td><td>-җөмлә, сүзтезмә һәм сүзләрне аерырга;<br><br>-сораулар ярдәмендә сүзтезмә һәм җөмләләрдәге сүзләр арасындагы бәйләнешне табарга;<br><br>-җөмләнең әйтү максаты буенча төрен</td><td>-җөмләнең иярчен кисәкләрен – аергыч, тәмамлык, хәлләрне аеру,дәреслектә тәкъдим ителгән үрнәк буенча гади җөмләгә синтаксик анализ (җөмлә кисәкләре буенча) ясау һәм аны тикшерүнең</td></tr>
</table>

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | аерырга;<br><br>-җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен билгеләргә;<br><br>-тиңдәш кисәкле һәм тойгылы җөмләләрне интонациясе буенча билгеләргә өйрәнә. | дөреслеген бәяләү, гади һәм кушма җөмләләрне бер-берсеннән аеру мөмкинлеге ала. | аналогияләрне таба, сәбәп-нәтиҗә элемтәләрен урнаштыра, логик фикерләү күнекмәләре: мөһим һәм аннан бәйле сүзләрдән торган логик чылбыр төзү;<br><br>ике яки берничә предметның, күренешнең гомуми билгесен табу, аларның | үзләштерү;<br><br>төрле яшь кысаларында укучыларның мәктәп үзидарә эшендә һәм иҗтимагый тормышта катнашу;<br><br>яшүсмерләрнең иҗтимагый оешмаларында катнашырга әзер тору; бердәм |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | охшашлыгын аңлату;<br><br>аерым билгеләре буенча предмет һәм күренешләрне берләштерү, чагыштыру, классификацияләү, факт һәм күренешләрне гомумиләштерү;<br>фикер йөртүне предметларны һәм күренешләрне чагыштыру һәм гомуми билгеләрне аерып алу нигезендә төзү.<br><br>-уку һәм танып-белү мәсьәләләрен чишү өчен билге, символ, модель, схемаларны үзгәртү һәм куллана белү<br>күнекмәсе: предмет һәм күренешләрне билге һәм символлар белән билгели;<br>предмет һәм күренешләр арасындагы логик бәйләнешне билгели, аларны билге, схемалар аша күрсәтү; мәсьәләнең шарты яки чишелү ысулы нигезендә модель, схема төзү. | башкарыла торган эшчәнлеккә уңай караш тудыру;<br><br>башка шәхескә хөрмәт;<br><br>анализ ясау, проектлаштыру эшчәнлеген оештыру;<br><br>үзендә лидерлык сыйфатларын тормышка ашыру ысулларын формалаштыру.<br><br>-сәламәт һәм куркынычсыз яшәү рәвеше кыйммәтләренең формалашуы;<br>кеше тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янаучы (тудыручы) гадәттән тыш хәлләрдә коллектив һәм индивидуаль үз-үзенне тоту, юлларда, транспортта үзеңне тоту кагыйдәләрен формалаштыру. |
| Бәйләнешле сөйләм үстерү | -аралашу даирәсенә карап, тиешле сүзләрне сайларга;<br><br>- көндәлек аралашуга бәйле татарча сөйләм әдәбе формаларын дөрес | -тәкъдим ителгән исемнең эчтәлегенә туры килгән текст төзү, бирелгән текстның эчтәлеген тулысынча яки сайлап сөйләү, сөйләмнең сурәтләү, | -аңлап уку: үз эшчәнлеге максатларына туры килгән, соралган информацияне тексттан табу.<br><br>-экологик фикерләүне формалаштыру һәм үстерү, аны танып-белү: табигый | -дөнья һәм Рәсәй халыкларының сәнгать мирасын аңлау, эстетик характердагы иҗади эшчәнлекне үзләштерү аша: төрле этномәдәни гореф-гадәтләрне чыгалдыручы әдәби әсәрләрне аңлау сәләте;гомуми рухи мәдәният, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | кулланырга;<br><br>-аралашу ситуациясен исәпкә алып, текстка карата үз мөнәсәбәтен белдерергә һәм аның дөреслеген дәлилләргә;<br><br>-текстка исем бирергә;<br><br>-укылган яки тыңлаган текстның планын төзергә;<br><br>-аерым аралашу ситуацияләренә туры китереп, хат яки тәбрикләү хаты кебек кечкенә текстлар язарга өйрәнә. | хикәяләү, фикер йөртү кебек төрләрен кулланып, билгеле бер тема буенча телдән хикәя төзү, урыннары алышынган җөмләләрдән торган текстны тикшерү һәм төзәтү, аның мәгънә бөтенлеге югалган урыннарын табу, хаталы текстларга төзәтмә кертү, төрле төрдәге изложение яки сочинение язганда, эшне эзлекле алып бару, аны тикшерү һәм бирелгән үрнәк белән чагыштыру, уку бурычларының дөреслеген бәяләү, үз текстын, аралашу максаты һәм шартыннан чыгып, чыганак (беренчел) текст белән чагыштыру, электрон чыганаклардан файдаланганда, тел нормаларының үтәлешен саклау мөмкинлеге | тирәлеккә үзенең мөнәсәбәтен билгели белү;<br><br>экологик белемнәрне тарату,<br><br>проект эшләр, модельләр, сочинениеләр, рәсемнәр аша табигатькә үз мөнәсәбәтеңне белдерү.<br><br>-сүзлекләр, башка эзләнү схемаларын актив куллана белү сәләтен мотивлаштыруны үстерү;<br><br>Коммуникатив күнекмә.<br><br>-укытучы һәм яшьтәшләре белән бердәм эшчәнлекне оештыра, индивидуаль һәм төркемдә эшли белү күнекмәсе булдыру. Дәлилле итеп үз фикерен башкаларга җиткерә белү;<br><br>-үз хисләреңне, фикерләреңне бирү, үз эшчәнлегеңне планлаштыру; язма һәм телдән, монологик һәм контекст сөйләм төрләрен оста файдалана белү;<br><br>-информацион-коммуникатив технологияләр өлкәсендә компетентлыкны формалаштыру һәм | тормышны танып-белүнең үзенчәлекле ысулы һәм аралашуны оештыру чаралары буларак, укучыларда әдәби культура нигезләрен формалаштыру; әйләнә-тирә дөньяны эстетик, эмоциональ кыйммәт аша күзаллау; үз-үзеңне күрсәтү һәм мәдәниятнең әдәби, әхлакый киңлегендә ориентлаша белү сәләте; кеше матурлыгын аңлау аша, үз илеңнең мәдәният тарихына хөрмәт; әдәби әсәрләрне өйрәнү ихтыяҗы булу; мәгънәви, эстетик һәм шәхескә юнәлтелгән кыйммәт буларак, әдәби мәдәниятнең гореф-гадәтләренә актив мөнәсәбәт формалаштыру. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | ала. | үстерү: уку һәм практик мәсьәләләрне чишү өчен кирәкле информацион ресурсларны ИКТ чаралары аша эзләргә һәм максатчан кулланырга; информацион һәм коммуникатив уку мәсьәләләрен чишү өчен,шулай ук: хат язу, сочинение, презентацияләүдә компьютер технологияләрен. | |

**Татар теле буенча укыту фәненең эчтәлеге 1 сыйныф**

| Бүлек исеме | Кыскача эчтәлек | Сәгать саны |
|---|---|---|
| Әзерлек чоры | Дәфтәр битләрендә ориентлашу. Туры сызык язу. Вертикаль, горизонталь һәм авыш сызыклар турында белешмә.Кыска һәм озын туры сызык язу.Бер яктан ыргаклы туры сызык язу.Ике яктан ыргаклы туры сызык язу.Өстән һәм астан элмәкле сызык язу. Элмәкле ярым озынча түгәрәк язу.Сулдан өстән һәм уңнан астан ыргаклы йөзмә сызык язу.Озынча һәм ярым озынча түгәрәк язу.Ярты озынча түгәрәкле сызык язу. Чирек озынча түгәрәкле кыска туры сызык язу | 11 |
| Әлифба чоры | Барлык баш һәм юл хәрефләренең язылышы һәм аларның тоташтыруның төп сызыклары белән таныштыру һәм каллиграфик дөрес язарга өйрәтү. Авазларны сүздә тиешле язма хәрефләр белән күрсәтү. Сүздәге хәрефләрне, аларны тоташтырган сузыкларын өзмичә ритмик язуны (ас-ос) булдыру , дәфтәр юлларына хәрефләрне һәм сүзләрне, тигез ара калдырып, тигез, дөрес урнаштыру. Башта укытучы белән иҗек –аваз анализы ясаганнан соң, тора бара мөстәкыйль рәвештә сүзләр, җөмләләр язу | 57 |
| Әлифбадан соңгы чор | Басмачадан текстны күчерү.Аңлатмалы диктант. | 2 |
| Алфавит | “Татар теле ” дәреслеге белән таныштыру. Алфавит.Хәрефләрне дөрес итеп уку (әйтү). Алфавиттагы | 3 |

| | | |
|---|---|---|
| | хәрефләрнең урынын белү. Алфавит Китапларны киштәләргә авторларының баш хәрефләренә карап урнаштыра белү. Сүзлекләр төзүдә алфавитның әһәмияте.Алфавит турындагы белемнәрне ныгыту. | |
| Авазлар һәм хәрефләр | Сузыклар. Калын һәм нечкә сузыклар. Иҗек. Сүзләрне юлдан-юлга күчерү.Тартык авазлар. Яңгырау һәм саңгырау тартыклар. Парлы һәм парсыз тарык авазлар.Э – е хәрефләре.Ө – е хәрефләре.О – ы хәрефләре.Я хәрефе.Ю хәрефе.Е, е хәрефләре.Й хәрефе.В хәрефе.К,г хәрефләре.М, н, ң хәрефләре. | 11 |
| Сүз төркемнәре | Предмет атамасын белдергән сүзләр — исемнәр белән таныштыру. Аларның мәгънәләрен аңлату, сорауларын әйтү; уртаклык һәм ялгызлык исемнәр һәм аларның язылышы.Исем, фамилия. Елга, күл, шәһәр, хайван кушаматларында баш хәрефләр. Исемнәр янында кулланыла торган ярдәмче сүзләр — бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр , өстәмә сүзләр белән таныштыру.Предметның билгесен белдергән сүзләр белән таныштыру.Эш-хәрәкәтне белдергән сүзләр — фигыльләр белән таныштыру. | 8 |
| Телдән һәм язма сөйләм | Телдән һәм язма сөйләм. Басым. Телдән сөйләмнең үзенчәлекләре (интонация, сүз басымы). Язма сөйләм үзенчәлекләре (җөмлә башында, ялгызлык исемнәрдә баш хәреф). Анда сүзнең *кем?* яки *нәрсә?* турында баруын һәм алар хакында нинди яңалык хәбәр ителүен белдерә торган кисәкләр. Аерым сүзләрдән җөмләләр төзү. Төрле интонация белән әйтелгән җөмләләрдән соң куелган тыныш билгеләре. Әзер тексттан сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне дөрес итеп күчереп язу. Аннан соң аларны укытучы әйтүе буенча язу, ул тәкъдим иткән сүзләрдән сүзтезмә һәм җөмләләр төзү.Аерым темалар буенча өйрәнгән сүзләрне, сүзтезмә һәм җөмләләрне диктант итеп язу. Матур язу күнегүләрен үтәү. Сөйләм күнекмәләре булдыру өстендә даими эшләү. | 7 |
| **Барлыгы** | | **99 сәг** |

**Өйрәнәсе фәннең эчтәлеге 2 класс**

| Бүлек исеме | Кыскача эчтәлек | Сәгать саны |
|---|---|---|
| Фонетика һәм орфоэпия | Аваз белән хәреф арасындагы аерманы аңлау; туган тел авазларына характеристика бирү: калын /нечкә сузыклар; парлы/парсыз, яңгырау/ саңгырау тартыклар;<br>Сүздәге басымлы һәм басымсыз авазларны табу. Сузык һәм тартык авазларга характеристика бирү.<br>Татар теленә генә хас булган авазларны дөрес әйтү. Сүзне иҗекләргә аеру, иҗекләр санын билгеләү. Күчереп язганда һәм әйтеп яздырганда өйрәнелгән кагыйдәләрне куллану. | 37 |

| | | |
|---|---|---|
| Графика | Аваз һәм хәрефләрне аеру: аваз билгесе буларак хәреф. Алфавиттагы хәрефләр тәртибен белү, сүзләрне алфавит тәртибендә урнаштыру өчен һәм кирәкле мәгълүматны тапканда алфавиттан файдалану. | 4 |
| Сүз | Тексттан тамырдаш сүзләрне табу. Тамырдаш сүзләрне аеру һәм тамырын билгеләү. Тамырдаш сүзләрне һәм сүз формаларны аеру. Сүзнең төп өлешен табу. Кем? Нәрсә? сорауларына җавап бирә торган исемнәрне белү. Уртаклык һәм ялгызлык исемнәрен танып белү.<br>Нинди? Кайсы? сорауларына җавап бирә торган сыйфатларны танып белү. Сөйләмдә сыйфатларны дөрес куллана белү. Нишли? Нишлиләр? Нишләр? Нишләрләр? сорауларына җавап бирә торган фигыльләрне тану һәм сөйләмдә дөрес куллана белү. | 40 |
| Җөмлә | Җөмләне сүзләр төркеменнән аеру, аның чикләрен билгеләү. Сүзләрдән җөмләләр төзү. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен табу. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр төзү. Җөмләдәге сүзләр бәйләнешен көйләү. Бирелгән сүзләрдән җөмлә төзү. Җөмләдәге барлык сүзтезмәләрне табу. Җыйнак һәм җәенке җөмләләрне аеру. Әйтү максаты һәм эмоциональ бизәге буенча җөмләнең өч төрен билгеләү. | 7 |
| Бәйләнешле сөйләм | Текстның темасын һәм төп фикерен билгеләү. Текстка исем бирү, текст белән аның исемен туры китерү. Тәкъдим ителгән башлам өлеше һәм терәк сүзләр ярдәмендә рәсем буенча хикәя төзү.<br>Текстның планын төзү һәм аны телдән сөйләгәндә һәм язмача хикәялэгәндә куллану. Текстта мәгънәле кисәкләрне билгеләү. Билгеләнгән темага, төрле сөйләм типларын кулланып, хикәя төзү: тасвирлау, хикәяләү, фикерләү; сөйләм этикетының, сөйләм әдәбенең (укучылар һәм өлкәннәр белән аралашканда) төп кагыйдәләрен ныгыту; өйрәнелгән сүзлек байлыгы нигезендә әдәби сөйләмнең төп кагыйдәләрен үзләштерү. | 14 |
| Барлыгы | | 102 |

**Татар теле буенча укыту фәненең эчтәлеге 3 сыйныф**

| **Бүлек исеме** | **Кыскача эчтәлек Бүлекнең төп эчтәлеге** | **Сәгать саны** |
|---|---|---|
| *Орфограмма. 1-2нче классларда үткәнне кабатлау.* | Беренче һәм икенче сыйныфларда алган белемнәрне, эш осталыгын һәм күнекмәләрне ныгыту, тирәнәйтү. Калын һәм нечкә сузыклар. Яңгырау һәм саңгырау тартыклар. Тавышсыз хәрефләр. Парлы һәм парсыз яңгырау һәм саңгырау тартыклар. Калын һәм нечкә сузык авазлар. Е,я,ю хәрефләренең сүз башында һәм сузык авазлардан соң ике аваз белдергән очракларын танып белү һәм шул хәрефләр кергән сүзләрне дөрес уку, күчереп язу. ъ, ь хәрефләренең аваз белдермәгәнлеген истә тоту, шул хәрефләр кергән | 10 |

| | | |
|---|---|---|
| | сүзләрне дөрес уку. Сүзгә фонетик анализ ясау. | |
| Сүз. Телнең сүзлек байлыгы. | Сүз. Сүзнең лексик мәгънәсе. Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр. Синонимнар. Антонимнар. Омонимнар. Аларның сөйләмдәге роле. Сүзнең күп мәгънәлелеген һәм күчерелмә мәгънәсен (фразеологик әйтелмәләр) куллану. Татар теленең сүз байлыгы. Дәреслекләрдәге сүзлекчәләрдән, сүзлекләрдән сүзнең аңлатмасын табып алу. Тотрыклы сүзтезмәләр | 8 |
| Сүз төзелеше. Сүз ясалышы | Морфология һәм аның состав өлешләре. Бер тамырдан берничә сүз ясалу, кушымчалар, аларның яңа сүз ясаудагы роле.<br>Тамырдаш сүзләр. Сүзләрнең ясалыш буенча төрләре (ясалма, кушма, парлы сүзләр). | 8 |
| *Сүз төркемнәре*<br>Исем | Сүз төркемнәре төшенчәсе.<br>Исем. Исемнең предметлык төшенчәсен белдерүе, аның җөмләдә ия булып килүе. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Исемнәрне тематик төркемләү. Исемнең берлек һәм күплек санда килүе. Күплек кушымчалары, аларның дөрес әйтелеше һәм ясалышы. Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Татар телендә килешләр һәм аларның сораулары. Сузык авазларга һәм яңгырау тартыкларга беткән исемнәрнең килешләр белән төрләнүе. | 9 |
| Фигыль | Фигыль сүз төркеменең мәгънәсе һәм сораулары. Фигыльнең барлык һәм юклык төрләре. Фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. Хикәя фигыль өч заманы: үткән заман, киләчәк заман, хәзерге заман. Фигыльнең заман формаларын дөрес ясау. Фигыльнең күп мәгънәлелеге. | 16 |
| Сыйфат | Исем+сыйфат төзелмәләре. Сыйфат дәрәҗәләре. Сыйфатның чагыштыру дәрәҗәсе. Сыйфатның артыклык дәрәҗәсе. Сыйфатның исемне ачыклап килүе, җөмләдәге роле. Сыйфатның чагыштыру дәрәҗәсен җөмләләрдә куллану. | 9 |
| Алмашлык | Зат алмашлыкларының иялек, юнәлеш, урын-вакыт килешләрендә сөйләмдә кулланышы. Ничә? Ничәдә? сораулары. Кая? Кайда? Кайдан? сораулары, *Кайда яши*? төзелмәсе. Нәрсә? Нәрсәне? Нәрсәнең? сораулары. Кемдер, нәрсәдер, нидер? Билгесезлек алмашлыклары. *Монда, анда, тегендә алмашлыкларын* җөмләдә куллану.Кемдер, нәрсәдер алмашлыклары белән таныштыру. | 5 |
| Кисәкчәләр | Кисәкчәләр турында гомуми мәгълүмат. –мы/ме сорау кисәкчәләре | 5 |
| Бәйлекләр | *Кебек, турында* бәйлекләре. *Алдында, артында, астында, өстендә* бәйлек сүзләре. Ян, буй бәйлек сүзен юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешендәкуллану. *Кадәр, соң, кебек* бәйлекләре. *Буе* бәйлек сүзенең килеш белән төрләнеше. | 2 |
| *Җөмлә*<br>Синтаксис | Хикәя, сорау, өндәү (боеру), тойгылы җөмләләр. Аларны текстта аера белү. Җөмлә ахырында тыныш билгеләре. Җөмләнең әйтелү максаты буенча төрләренә карап, җөмлә ахырына тыныш билгесе кую. Җөмләнең баш кисәкләре . Язма сөйләмдә ия һәм хәбәрнең урыннары.<br>Җыйнак һәм җәенке җөмләләр. Җыйнак җөмләне, тиешле | 12 |

| | | |
|---|---|---|
| | сүзләр өстәп, җәенкеләндерә белү, җәенке җөмлә эченнән баш кисәкләрне генә аерып чыгару. | |
| Сүзтезмә | Сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне аера белү, мәгънәләре, сораулар ярдәмендә җөмләдә сүзләр бәйләнешен ачыклау, сүзтезмәдәге ияртүче һәм иярүче сүзләрне билгеләү. | 3 |
| БСҮ | Текстның темасын һәм төп фикере. Исемсез текстларның темасын билгеләү һәм исем кую. Төп фикерне темадан аера белү һәм аларны төгәл билгеләү. Текстның типлары: хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү. Аларның төп үзенчәлекләре.<br>Әзер яки күмәк төзелгән план буенча хикәяләү тибындагы текстны изложение итеп язу. Сюжетлы рәсемнәр һәм картиналар буенча укучыларның тормыш тәҗрибәсенә, күзәтүләренә, укыганнарына бәйле темаларга сочинениеләр язу. Телдән эш характерындагы текстлар төзү.<br>Сөйләм этикасы. Телдән һәм язмача чакыру, тәбрикләү. | 8 |
| Ел буена үткәннәрне кабатлау | Сүзнең төп(лексик) мәгънәсе. Синонимнар һәм антонимнар. Исем. Исемнәрнең килеш белән төрләнүе. Фигыль. Фигыльнең заман белән төрләнеше. Сыйфат. Сыйфат дәрәҗәләре. Алмашлык. Җөмләнең баш кисәкләре. Бәйләнешле сөйләм. Текст. Текстның планы. | 7 |
| Барысы | | 102 |

**Өйрәнәсе фәннең эчтәлеге 4 сыйныф**

| № | Бүлек исеме | Кыскача эчтәлек | Сәгать саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Фонетика. Графика | 4 нче сыйныфта татар теле дәресләре 1-3 нче сыйныфларда алган белемнәрне искә төшерүдән башлана.1-3 нче сыйныфларда укучылар тел фәненең төп бүлекләре- татар теленең фонетикасы, морфологиясе, синтаксисы буенча иң беренче мәгълүматларны алалар.<br>Татар телендә сингармонизм законы булуын аңлау. Хикәя, сорау, боеру җөмләләрне дөрес интонация белән укый белү | 8 |
| 2 | Лексикология | Сүзнең яңгыраш һәм мәгънә бердәмлеге булуын аңлау. Мәгънәсе төгәллек таләп итә торган сүзләрне ачыклау. Сүзнең мәгънәсен текст буенча яки аңлатмалы сүзлек ярдәмендә ачып бирү. Бер һәм күп мәгънәле, туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләрне табу. Сөйләмдә синоним һәм антонимнарның кулланылышына игътибар итү | 8 |
| 4 | Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы | Тамырдаш сүзләр турында төшенчә булдыру. Тамырдаш сүзләрне бер сүзнең төрле формаларыннан аеру. Тамырдаш сүзләрне омонимнардан аеру. Сүзләрдә | 11 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | тамыр һәм кушымчаны аерып күрсәтү. Сүз ясагыч кушымчалар турында төшенчә бирү. Тамырдаш сүзләрнең сүз ясагыч кушымчалар ярдәмендә ясалуы. Сүз төзелешен тикшерү күнегүләрен үтәү | |
| 5 | Морфология | Сүз төркемнәре турында төшенчә бирү. Исем, аның мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Ялгызлык исемнәрне таба белү. Кем? Нәрсә? сорауларына җавап биргән исемнәрне аеру. Исемнәрнең сан формалары. Исемнәрнең килеш белән төрләнеше, аларның килешләрен билгеләү. Килеш сораулары. Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. Исемнәргә морфологик анализ ясау.<br><br>Сыйфат, аның мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Сыйфатның сораулары. Сыйфатның төс, тәм, форма, күләм, характер һ.б. билгеләрне белдерүе. Сыйфат дәрәҗәләре. Сыйфатның исемгә бәйләнеп килүе. Сыйфатка морфологик анализ ясау.<br><br>Алмашлык. Алмашлык турында гомуми төшенчә. Зат алмашлыклары, аларның мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. I, II, III зат алмашлыклары, аларның берлек һәм күплек сан формалары, килеш белән төрләнеше.<br><br>Фигыль. Мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. Нишли? Нишләде? Нишләр?сорауларына җавап биргән фигыльләрне аеру. Фигыльнең зат-сан белән төрләнүе, төрле заман формалары (хәзерге, үткән, киләчәк заманнар). Фигыльнең барлык һәм юклыкта килүе. Фигыльләргә морфологик анализ ясау.<br><br>Рәвеш, аның мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы.<br><br>Кисәкчәләр<br>(да, дә, та, тә, гына, генә, кына, кенә, ук, үк, ич, бит).<br>Аларның дөрес язылышы | 51 |
| 6 | Синтаксис | Җөмлә, сүзтезмә һәм сүзләрне аеру, аларның охшаш һәм аермалы якларын аңлау. Әйтү максаты ягыннан хикәя, сорау, тойгылы һәм боеру җөмләләр, аларны дөрес интонация белән уку. Җыйнак һәм җәенке гади җөмлә.<br>Җөмләнең баш кисәкләре. Баш һәм иярчен кисәкләрнең аермасы. Сүзтезмәдәге сүзләр һәм җөмлә кисәкләре арасында мәгънәви сораулар ярдәмендә бәйләнеш булдыру.<br>Теркәгечле (һәм, ә, ләкин) һәм теркәгечсез тиңдәш кисәкле җөмләләрне табу һәм мөстәкыйль рәвештә төзү. Тиңдәш кисәкле җөмләләрдә санау интонациясе.<br>Гади һәм кушма җөмләләрне аеру | 12 |
| 7 | Бәйләнешле сөйләм үстерү | Аралашу ситуациясен – аралашу кем белән, кайда, нинди максат белән башкарылуын аңлау. Үз фикереңне | 12 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | эйтү һәм аны дәлилләү. Әңгәмә үткәрүнең төп күнекмәләрен үзләштерү (сүз башлау, әңгәмәгә кушылу, аны дәвам итү, игътибарны җәлеп итү һ.б.). Уку, көндәлек аралашу шартларында тел әдәбе нормаларын үзләштерү (сәламләү, хушлашу, гафу үтенү, рәхмәтле булу, сорау белән мөрәҗәгать итү). Татар телен йомшаграк белүче кешеләр белән аралашканда сөйләм әдәбе үзенчәлекләре.<br>Билгеле бер темага караган төрле (сурәтләү, хикәяләү, фикерләү характерындагы) сөйләм текстлары кулланып, телдән монологик сөйләмне гамәли яктан үзләштерү.<br>Текст. Текст билгеләре. Тексттагы җөмләләрнең мәгънәви бердәмлеге. Текстка исем бирү.<br>Тексттагы җөмләләрнең эзлеклелеге. Текст кисәкләренең (өлешләренең) эзлеклелеге, кызыл юл турында төшенчә.<br>Текстка исем бирү, җөмлә һәм текст кисәкләрен билгеләү, җөмлә һәм текст кисәкләре эзлеклелеген төзәтү.<br>Текстның планын төзү. Бирелгән план буенча үз текстыңны төзү.<br>Сурәтләү һәм хикәяләү характерындагы текстлар, аларның үзенчәлекләре.<br>Котлау тексты һәм хат язу. Язма сөйләмнең төгәллеген, дөреслеген һәм сәнгатьлелеген саклап, үз текстыңны төзү һәм бирелгән текстларны тикшереп төзәтү, текстта синонимнар, антонимнар куллану.<br>Изложение һәм сочинениенең төп төрләре белән танышу (билгеләмәләрен ятламыйча): бирелгән текстны тулысынча файдаланып яки аерым урыннарын (сүзләрен) сайлап алып языла торган изложение, сочинение элементлары булган изложение, хикәяләү-сурәтләү рәвешендәге сочинение һ.б | |
| | *Барлыгы* | | 102 |

Прошито и пронумеровано и скреплено печатью 26 страниц (двадцать шесть)

Должность, директор школы

ФИО Иванов С.В

(подпись) М.П.

«___» ____________ 2019 года

МБОУ "Ниж...бишевская СОШ"